**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

**(III чакырылыш)**

**чираттан тыш утырыш КАРАРы**

2019 елның 19 сентябре №30 Урыссу штб

Татарстан Республикасы Ютазы

муниципаль районы Башкарма комитеты

җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс

үткәрү турында

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылу сәбәпле, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 маддәсенә, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 маддәсенә, район Советының 2015 елның 11 сентябрендәге карары белән расланган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 47, 51 маддәләренә таянып, Ютазы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2019 елның 11 октябрендә, 14.00 сәгатьтә, Урыссу ш.т. б., Пушкин ур., 38 йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының утырышлар залында Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс үткәрергә .

2. Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасы - Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучылардан конкурс документларын 2019 елның 20 сентябреннән 2019 елның 9 октябренә кадәр Урыссу ш.т.б., Пушкин ур., 38( 3 кат) адресы буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Советы бинасында кабул итәргә: Ютазы муниципаль районы Советының кадрлар

бүлеге секторы мөдире кабинеты, ял һәм бәйрәм көннәреннән тыш, көн саен, 8 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр, телефон - 8 (84360) 2-79-7, факс 8 (84360) 2-62-20.

3. Татарстан Республикасы Президентының 2019 елның 19 июлендәге «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетлары җитәкчеләре вазыйфаларын биләүгә кандидатураларны карау өчен конкурс комиссияләре әгъзаларын билгеләү турында» ПУ-419 санлы Указын исәпкә алып, Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру өчен конкурс комиссиясе төзергә һәм аның составын №1 кушымтага ярашлы расларга.

4.Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибен 2 нче кушымтага ярашлы расларга .

5. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе белән контракт шартларын 3 нче кушымта нигезендә расларга.

6. Әлеге карарны «Ютазы таңы» («Ютазинская новь») газетасында бастырып чыгарырга һәм Ютазы муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгыма алам.

Рәислек итүче,

2 санлы Акбаш сайлау округы буенча депутат Төхбәтуллин С. Р.